Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге составына керүче Шумково авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

16 ноябрь 2022 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шумково авыл җирлеге составына керүче Шумково авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Шумково авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан,1 нче төркем инвалидлардан һәм өлешчә мобилизацияләүгә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- Шумково авылында урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту (светодиод яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);
- Шумково авылындагы урамнарны кышкы карап тоту (карны чистарту) ;
- Мелиорация урамындагы су башнясын ремонтлау;
- Шумково авылында су белән тәэмин итү системаларын (скважиналарны) рәсмиләштерү һәм су насосы сатып алу чыгымнарын финанслау.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шумково авылы,Үзәк урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Олы Укмас авылы, Үзәк урамы,42 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы Хутор авылы, Яшьләр урамы, 5 йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шумково авыл җирлеге Башлыгы: Л.М.Назмиев

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РЫБНО-СЛОБОДСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ ШУМКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1634000845
ШУМКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ